КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 21 август г.Казань № 621

Татарстан Республикасындагы социаль ипотека системасында торак шарталарын яхшыртуга мохтаҗ махсус хәрби операциядә катнашкан затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына торак урыннары бирү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасындагы социаль ипотека системасында торак шарталарын яхшыртуга мохтаҗ махсус хәрби операциядә катнашкан затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына торак урыннары бирү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә торган махсуслаштырылган оешма торак урыннар бирү буенча вәкаләтле оешма булып тора дип билгеләргә.

3. Социаль ипотека системасында махсус хәрби операциядә катнашкан затлар һәм аларның гаилә әгъзалары өчен билгеләнгән торак урыннар махсуслаштырылган оешманың югары күмәк идарә органы белән килештерелгән күләмдә бүлеп бирелә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин